ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш  авылы торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү турында

14ноябрь 2025ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлегенен  Игәнә-Баш авылында  гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:
1 Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз  авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, 90 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан һәм ашыгыч хезмәт узучы көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда үзара салым кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

1) Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту (махсуслаштырылган техникага - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ГСМ, запас частьләр сатып алу);
2) Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту (Игәнә-Баш авылындагы юлларны кардан чистарту (йөртүче хезмәтләре өчен түләү);
3)Игәнә-Баш торак пунктында урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар, яктырткычлар сатып алу);
4) Юл читләрен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

3. Иляксаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Иляксаз авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы И.Х.Хадиуллин